Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXII-1**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 23 октябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2012 елның 29 декабрендәге “Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына акчалата бүләкләүләр, вазыйфаи эш хаклары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында”гы XXIII-3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга социаль гарантияләрне тәэмин итү, хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 маддәсе, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 26 маддәсе, “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында” 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы контроль-хисап органнары рәисләренең хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында” 2007 елның 17 декабрендәге 722 номерлы карары, “Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи эш хакларының, акчалата бүләкләү күләмнәрен индексацияләү турында” 2013 елның 30 сентябрендәге 705 номерлы, “Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең

айлык вазыйфаи эш хакларының, акчалата бүләкләү күләмнәрен индексацияләү турында” 2017 елның 28 июлендәге 525 номерлы, “Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алуга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә түләү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 2005 елның 29 декабрендәге 666 номерлы карары, “Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затларга түләүләр тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2006 елның 10 июлендәге 353 номерлы Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасыннан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә акчалата түләү тәртибен раслау турында” карарлары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2012 елның 29 декабрендәге “Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына акчалата бүләкләүләр, вазыйфаи эш хаклары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында”гы XXIII-3 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 15 февралендәге XVI-6 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) преамбуладагы “Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында” 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы” сүзләрен “Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы” сүзләренә алмаштырырга;

1.2) 1 пунктта:

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“14 нче кушымта нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәргә бер мәртәбә акчалата кызыксындыру түләү тәртибе турында нигезләмә;”;

түбәндәге эчтәлектәге уналтынчы абзацны өстәргә:

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга муниципаль вазыйфадан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә акчалата бүләкләүне гамәлгә ашыру тәртибе турында нигезләмә, 15 нче кушымта нигезендә;”;

уналтынчы абзацны унҗиденче абзац дип санарга һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү фондын төзү тәртибе 16 нчы кушымта нигезендә.”;

1.3) 1 нче кушымтаны яңа редакциядә әлеге карарга кушымта нигезендә бәян итәргә;

1.4)2 нче кушымтаны яңа редакциядә әлеге карарга кушымта нигезендә бәян итәргә;

1.5) 6 нчы кушымтада аталышка “кызыксындыру” сүзен өстәргә;

1.6)9 нчы кушымтаны яңа редакциядә әлеге карарга кушымта нигезендә бәян итәргә;

1.7)14 нче кушымтаны яңа редакциядә әлеге карарга кушымта нигезендә бәян итәргә;

1.8) әлеге карарга кушымта нигезендә 15 нче кушымтаны өстәргә;

1.9) 15 нче кушымтаны 16 нчы кушымта дип санарга һәм аны яңа редакциядә әлеге карарга кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә үз хокукый актларын әлеге карарга туры китерүне йөкләргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә һәм 2017 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2012 елның 29 декабрендәге
XXIII-3 номерлы карарына
кушымта №1

(Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 23 октябрендәге XXII-1 номерлы карары редакциясендә)

Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга, муниципаль районның контроль-хисап органы рәисенә хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары

| Вазыйфаның аталышы | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 8 төркем |
| Муниципаль район Башлыгы | 29555 |
| Муниципаль район Башлыгы урынбасары | 26598 |
| Муниципаль районның Контроль-хисап органы рәисе | 26598 |

Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларын акчалата бүләкләү күләмнәрен билгеләү өчен тиңдәшле рәвештә муниципаль берәмлек статусына һәм аның территориясендә даими яшәүче халык санына карап, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен хезмәткә түләү төркемнәренә кертү күрсәткечләре кертелә.

Күрсәтелгән күрсәткечләргә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге сигезенче төркемгә кертелде – башка муниципаль районнар халык санына бәйсез рәвештә.

2009 елның 12 февралендәге “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында”15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль вазыйфаны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында даими нигездә биләүче затка (алга таба – муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче зат) Татарстан Республикасы норматив актлары белән башкасы каралмаган очракта айлык акчалата бүләкләүдән (хак түләү) гайре өстәмә рәвештә билгеләнә:

1) матди ярдәм;

2) ай саен акчалата кызыксындыру;

3) эш нәтиҗәләре буенча премия;

4) еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү;

5) федераль законнар һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр.

Муниципаль район Башлыгына, еллык түләүле отпуск биргәндә айлык акчалата бүләкләүдән һәм бер мәртәбә түләүдән тыш, ай саен акчалата кызыксындыру, эш нәтиҗәләре буенча премияләр түләнә, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр дә башкарылырга мөмкин. Шул ук вакытта муниципаль район Башлыгына айлык акчалата түләүләрнең җыелма күләме Татарстан Республикасы министрына акчалата түләүләрнең 0,9 айлык җыелма күләменнән артык була алмый.

Муниципаль район Башлыгы урынбасарына, айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләүдән тыш, өстәмә рәвештә айлык акчалата кызыксындырулар, эш нәтиҗәләре буенча премияләр түләнә ала, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр башкарыла ала. Шул ук вакытта муниципаль район Башлыгы урынбасарының айлык акчалата түләүләренең гомуми күләме муниципаль район Башлыгының айлык акчалата түләүләренең 0,55 күләменнән артык була алмый.

Муниципаль районның контроль-хисап органы рәисенә, айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләүдән тыш, өстәмә рәвештә айлык акчалата кызыксындырулар, эш нәтиҗәләре буенча премияләр түләнә ала, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр башкарыла ала. Шул ук вакытта аның айлык акчалата түләүләренең гомуми күләме муниципаль район Башлыгының айлык акчалата түләүләренең 0,55 күләменнән артык була алмый.

Еллык түләүле отпускны муниципаль район башлыгына, муниципаль район башлыгы урынбасарына, депутатларга, контроль-хисап органы рәисенә биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләү елына бер айлык акчалата түләүдән артмаган күләмдә түләнә.

Муниципаль район Башлыгына, муниципаль район Башлыгы урынбасарына, контроль-хисап органы рәисенә матди ярдәм бала туганда, тантаналы, юбилей датасына, шулай ук көчле чир авырганда, үлемендә һәм сайланулы вазыйфаи затның һәм (яисә) якын туганнарының башка бәхетсезлек очракларында түләнергә мөмкин. Матди ярдәм түләү хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбенә башкарыла, матди ярдәм түләү өчен нигез булып муниципаль хокукый акт тора, ул түбәндәге очракларда рәсмиләштерелә:

муниципаль район Башлыгына - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 69 маддәсендәге 2 өлеше нигезендә чыгарылган муниципаль район Башлыгы урынбасары күрсәтмәсе;

муниципаль район Башлыгы урынбасарына, контроль-хисап органы рәисенә - муниципаль район Башлыгы күрсәтмәсе.

Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр муниципаль

вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәте өчен түләү фонды чикләрендә түләнә.

Даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар шулай ук Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый үсешендә нәтиҗәләргә ирешүгә керткән өлешләре өчен, шулай ук дәүләт, муниципаль яки һөнәри бәйрәмнәр, җирле бюджет акчалары хисабына истәлекле яки юбилей даталары белән бәйле рәвештә премияләргә лаек була алалар.

Даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга премия түләү өчен нигез булып, рәсмиләштерелгән муниципаль хокукый акт тора:

муниципаль район Башлыгына - Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 69 маддәсендәге 2 өлеше нигезендә чыгарылган муниципаль район Башлыгы урынбасары күрсәтмәсе;

муниципаль район Башлыгы урынбасарына, контроль-хисап органы рәисенә - муниципаль район Башлыгы күрсәтмәсе.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2012 елның 29 декабрендәге
XXIII-3 номерлы карарына
кушымта №2

(Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 23 октябрендәге XXII-1 номерлы карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи эш хаклары

| N п/п | Вазыйфаның аталышы | Вазыйфаи эш хакы, сумнарда |
|---|---|---|
| | | 8 төркем |
| 1. | Башкарма комитет җитәкчесе | 6882 |
| 2. | Совет аппараты җитәкчесе | 6198 |
| 3. | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 6123 |
| 4. | Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе | 6123 |
| 5. | Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 5610 |
| 6. | Башкарма комитет аппараты идарәсе башлыгы | 5295 |
| 7. | Мөстәкыйль бүлек башлыгы, Башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе (аппараты) башлыгы | 4508-5062 |
| 8. | Башкарма комитет аппаратының идарә башлыгы урынбасары | 5062 |
| 9. | Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары, башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 4508 |
| 10. | Муниципаль район башлыгы ярдәмчесе | 4508 |
| 11. | Башкарма комитет идарәсе составындагы бүлек башлыгы | 4508 |
| 12. | Сектор мөдире | 3968 |
| 13. | Баш белгеч | 3619 |
| 14. | Әйдәүче белгеч | 3277 |

Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи эш хаклары күләмнәрен билгеләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен тиешле муниципаль берәмлек статусына һәм аның территориясендә даими яшәүче халык санына бәйле рәвештә хезмәт өчен түләү төркемнәренә кертү күрсәткечләре кертелә.

Күрсәтелгән күрсәткечләргә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге сигезенче

төркемгә кертелгән – халык санына бәйсез рәвештә башка муниципаль районнар.

Муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенә вазыйфаи эш хакының күләме әлеге карар нигезендә билгеләнә. Шул ук вакытта айлык акчалата түләү күләме муниципаль район Башлыгына айлык акчалата түләүләрнең 0,6 күләменнән артык була алмый.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2012 елның 29 декабрендәге
XXIII-3 номерлы карарына
кушымта №9

(Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 23 октябрендәге XXII-1 номерлы карары редакциясендә)

Муниципаль хезмәткәрләргә матди ярдәм түләүне гамәлгә ашыру күләме һәм тәртибе

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә (алга таба - муниципаль хезмәткәрләр) матди ярдәм социаль характердагы түләүгә карый һәм тиешле еллар эшләгән өчен хезмәт окладына айлык өстәмә, муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен вазыйфа окладына айлык өстәмә, түләү көненә билгеләнгән классчы чин өчен хезмәт хакына айлык өстәмә, шулай ук әлеге карар тарафыннан билгеләнгән күләмдә айлык акчалата кызыксындыру күләмендә башкарыла.

2. Муниципаль хезмәттәге хезмәткәрләргә матди ярдәм күрсәтү агымдагы финанс елының декабрендә елга бер тапкыр муниципаль хезмәткәрнең матди ярдәм күрсәтү турындагы гаризасы нигезендә башкарыла.

Матди ярдәмнең конкрет күләме матди ярдәмнең билгеләнгән күләмен төзәтеп агымдагы елда эш көннәрендә башкарылган вакытка пропорциональ рәвештә исәпләнә, шул исәптән, нигездә, түләүле һәм өстәмә түләүле отпусклар, командировкада һәм эш бирүче инициативасы буенча квалификация күтәрү курсларында булу вакытын да кертеп.

Матди ярдәм суммасын исәпләп чыгару өчен фактта эшләнгән вакытта Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында, муниципаль хезмәт вазыйфаларында һәм башка вазыйфаларда өзлексез эшләү чоры кертелә, агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарәсенең бер башка органына эшкә алуны исәпкә алып.

3. Матди ярдәм түләү хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбенә башкарыла, матди ярдәм түләү өчен нигез булып муниципаль хокукый акт тора, ул түбәндәге очракларда рәсмиләштерелә:

муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесенә, муниципаль районның Финанс-бюджет палатасы рәисенә, муниципаль районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә - муниципаль район Башлыгы күрсәтмәсе;

юридик зат статусына ия булган муниципаль район Башкарма комитетының тармак (функциональ) органнары башлыкларына - муниципаль район Башкарма комитеты күрсәтмәсе;

башка муниципаль хезмәткәрләр өчен - муниципаль хезмәткәргә карата яллаучы вәкиленең (эш бирүченең) вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы затның хокукый акты.

4. Эшкә алучының (эш бирүче) вәкиле карары буенча матди ярдәм түбәндәге очракларда һәм күләмнәрдә өстәмә рәвештә (алга таба - өстәмә матди ярдәм) түләнергә мөмкин:

- муниципаль хезмәткәрнең каты чир белән  авыруы аркасында - муниципаль хезмәткәрнең биләгән вазыйфасы буенча өч акчалата түләү;

- муниципаль хезмәткәргә һәм (яисә) гаилә әгъзаларына, туганнарына матди зыян яисә сәламәтлеккә зыян килүне каплау максатларында стихияле бәла-казага яисә гадәттән тыш хәлгә бәйле рәвештә - муниципаль хезмәткәрнең биләгән вазыйфасы буенча өч акчалата түләү;

- ире (хатыны), балалары, муниципаль хезмәткәрнең ата-анасы вафат булу сәбәпле - ун мең сум;

- хатынының (иренең) һәм балаларының, муниципаль хезмәткәрнең ата-аналарының каты авыруы аркасында - ун мең сум;

- муниципаль хезмәткәрнең үлеме уңаеннан, үлем көненә ул муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән булса, муниципаль хезмәткәрне еллык тотуның акчалата күләмендә. Муниципаль хезмәткәрнең үлеме уңаеннан матди ярдәм хатынына (иренә) яисә балаларның яисә ата-ананың берсенә түләнә. Күрсәтелгән пособиене түләү тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән билгеләнә.

5. Финанс елында матди ярдәм түләүнең бер мәртәбә башкарылуы турындагы таләпләр муниципаль хезмәткәрне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының башка җирле үзидарә органына финанс елы дәвамында эшкә алу очракларына кагыла.

6. Өстәмә матди ярдәм түләү җирле үзидарә органнары хезмәте өчен түләү фондында каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла.

7. Өстәмә матди ярдәм түләүгә муниципаль хокукый акт нигез була, ул түбәндәгеләр тарафыннан рәсмиләштерелә:

муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе, муниципаль районның Финанс-бюджет палатасы рәисе, муниципаль районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе - муниципаль район Башлыгы күрсәтмәсе;

юридик зат статусына ия булган муниципаль район Башкарма комитетының тармак (функциональ) органнары башлыкларына - муниципаль район Башкарма комитеты күрсәтмәсе;

башка муниципаль хезмәткәрләр өчен - муниципаль хезмәткәргә карата яллаучы вәкиленең (эш бирүченең) вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы затның хокукый акты.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2012 елның 29 декабрендәге
XXIII-3 номерлы карарына
кушымта №14

(Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 23 октябрендәге XXII-1 номерлы карары редакциясендә)

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәргә бер мәртәбә акчалата кызыксындыру түләү тәртибе турында Нигезләмә

1. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль хезмәткәренә бер мәртәбә акчалата кызыксындыру түләү тәртибе турында әлеге Нигезләмә (алга таба – бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру) "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 26 маддәсе, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 31 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 12 маддәсе нигезендә эшләнде.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәттән (алга таба - муниципаль хезмәт) азат ителгәндә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәргә (алга таба - муниципаль хезмәт) муниципаль хезмәт стажы 15 ел булганда һәм муниципаль хезмәтнең һәр тулы елы өчен эштән азат ителгән көнгә биләп торучы муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча аның айлык акчалата хезмәт хакының биш мәртәбә күләмендә бер мәртәбә кызыксындыру түләнә – өстәмә рәвештә - 0,5 акчалата, әмма муниципаль хезмәткәрне тотуның акчалата ун күләменнән артмаска тиеш. Муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәттән киткән көнгә билгеләнә.

Әлеге Нигезләмәнең максатлары өчен тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыкканда муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 28 маддәсендәге 1 өлешенең 3 пунктында каралган нигезләрдә муниципаль хезмәттән азат ителү, "Иминият пенсияләре турында" 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль законның 8 маддәсендәге 1 өлеше нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәч аңлашыла, яки картлык буенча хезмәт пенсиясен вакытыннан алда яисә инвалидлык буенча хезмәт пенсиясен билгеләгәндә, муниципаль хезмәткәрнең гаепле гамәлләренә бәйле рәвештә эштән азат ителүдән тыш һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булганда.

3. Бер мәртәбә кызыксындыру түләү турындагы карар җирле үзидарә

органы җитәкчесе тарафыннан кабул ителә, бер үк вакытта Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органы (алга таба - җирле үзидарә органы) тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү турында карар кабул ителү белән рәсмиләштерелә.

4. Бер үк вакытта бүләкләү муниципаль хезмәткәр эштән чыгар алдыннан турыдан-туры хезмәт итә торган җирле үзидарә органы тарафыннан муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү (соңгы эш көне) көненнән дә соңга калмыйча түләнә.

5. Бер мәртәбә кызыксындыру күләмен билгеләү өчен җирле үзидарә органы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (алга таба - Финанс-бюджет палатасы) түбәндәге документларны тапшыра:

муниципаль хезмәткәрне айлык акчалата тоту турында белешмә;

җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган муниципаль хезмәттәге эш стажы турында белешмә;

кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе һәм хәрби билет күчермәләре;

классны чин бирү, муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата тоту составына керә торган вазыйфаи эш хакына өстәмә билгеләү турында боерыклардан (күрсәтмәләрдән) өземтәләр;

муниципаль хезмәткәрнең эш стажын билгеләү өчен законнар нигезендә кирәкле башка документлар.

6. Җирле үзидарә органы әлеге Нигезләмәнең 5 пункты нигезендә тиешле еллар эшләгән пенсиягә чыгу сәбәпле муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү көненә кадәр 30 календарь көн кала документларны тапшыра.

7. Бер мәртәбә бүләкләү күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык акчалата тоту составына түбәндәгеләр керә:

вазыйфаи эш хакы;

классны чин өчен вазыйфаи эш хакына өстәмәләр;

еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү күләменең 1/12 е;

айлык башка түләүләр:

тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка өстәмә;

вазыйфаи окладның 50 процентыннан артмаган күләмдә акчалата кызыксындыру;

дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка өстәмәләр;

муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү көненә кадәр кимендә 6 ай кала билгеләнгән күләмдә муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен вазыйфаи окладка өстәмә түләү;

махсус эш режимы өчен компенсация түләүләре, эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге;

вазыйфаи окладка профильле гыйльми дәрәҗә өчен өстәмә.

8. Җирле үзидарә органы әлеге Нигезләмәнең 5 пункты нигезендә документлар тапшырганнан соң 20 календарь көн эчендә финанс-бюджет палатасы муниципаль хезмәткәргә бер мәртәбә кызыксындыру өчен бюджет ассигнованиеләре турында һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары хакында җирле үзидарә органына хәбәр җиткерә (алга таба - хәбәрнамә) яисә бер мәртәбә кызыксындыру өчен җирле үзидарә органына акча бирүдән дәлилле баш тарту.

9. Финанс-бюджет палатасы, әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында каралган барлык документлар тапшырылмаган очракларда, җирле үзидарә органына бер мәртәбә кызыксындыру өчен акча бирүдән баш тарта.

10. Җирле үзидарә органы хәбәрнамә алган мизгелдән алып 10 календарь көн эчендә муниципаль хезмәткәргә бер мәртәбә кызыксындыруны түли.

11. Бер тапкыр кызыксындыру хезмәт кенәгәсендәге билге белән бер тапкыр түләнә. Гражданин тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыкканнан соң һәм муниципаль хезмәтне туктатканнан соң муниципаль хезмәткә кергәндә бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру кабат түләнми.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2012 елның 29 декабрендәге
XXIII-3 номерлы карарына
кушымта №15

(Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 23 октябрендәге XXII-1 номерлы карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга муниципаль вазыйфадан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата хак (бүләкләү) түләүне гамәлгә ашыру тәртибе турында
Нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга (алга таба-даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар) вәкаләтләр туктатылуга (шул исәптән вакытыннан алда) бәйле рәвештә даими нигездә биләнүче муниципаль вазыйфадан азат ителгәндә, “Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында” 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 маддәсенең 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча вәкаләтләр туктатылудан гайре, “Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында” 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә пенсиягә өстәмә түләү хокукы булганда һәм (яисә) “Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында” 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә даими нигездә биләгән муниципаль вазыйфадан эштән азат ителгәндә бер тапкыр бирелә торган акчалата хак (бүләкләү) түләнә.

2. Муниципаль вазыйфаны 2006 елның 1 гыйнварына даими нигездә биләүче затларга һәм (яисә) соңрак, шул исәптән депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вазыйфасын 1995 елның 5 мартыннан алып 2006 елның 1

гыйнварына кадәр даими нигездә биләүчеләргә, кимендә биш ел яисә җирле үзидарә органы вәкаләтләренең бер тулы срогы, әмма өч елдан ким түгел, бер тапкыр бирелә торган акчалата хак биләгән вазыйфасы буенча тотуга билгеләнгән биш айлык акча күләмендә һәм муниципаль вазыйфаны биләүнең һәр алдагы елында биләгән вазыйфа буенча билгеләнгән айлык акчалата сумманың 1/2 өлеше күләмендә өстәмә рәвештә түләнә, ләкин биләгән вазыйфасы буенча билгеләнгән унлатылган айлык акчалата түләү күләменнән артык түгел.

Бер тапкыр бирелә һәм түләнә торган акчалата хак (бүләкләү) составына әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә биләгән вазыйфа буенча билгеләнгән айлык акчалата кызыксындыру һәм айлык акчалата хак түләү кертелә.

3. Бер мәртәбә акчалата хак (бүләкләү) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарәсенең тиешле органы (алга таба - җирле үзидарә органы) тарафыннан түләнә, бу органда даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче зат вәкаләтләре (шул исәптән вакытыннан алда) туктатылу һәм (яисә) пенсиягә чыгу сәбәпле эштән азат ителү алдыннан гамәлгә ашыра.

4. Бер мәртәбә акчалата хак түләү күләмен билгеләү өчен җирле үзидарә органы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (алга таба - Финанс-бюджет палатасы) түбәндәге документларны тапшыра:

4.1) даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затның пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә акчалата хак түләү турында гаризасы;

4.2) пенсиягә чыгу сәбәпле муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затка бер мәртәбә акчалата хак түләү турында җирле үзидарә органының хокукый акты;

4.3) муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затны тотуның айлык акчалата күләме турында белешмә;

4.4) муниципаль һәм (яисә) дәүләт вазыйфасында, муниципаль һәм (яисә) дәүләт хезмәтендә эш стажы турында җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган белешмә;

4.5) җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе һәм хәрби билет күчермәләре;

4.6) муниципаль вазыйфаны даими нигездә җирле үзидарә органында биләүче затның эш стажын билгеләү өчен законнар нигезендә кирәкле башка документлар.

5. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче зат әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән гариза белән тиешле җирле үзидарә органына пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне түләүне гамәлгә ашыру өчен нигезләр барлыкка килгәннән соң бер елдан да соңга калмыйча мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Күрсәтелгән срок узганнан соң даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затның гаризасы пенсиягә чыгу сәбәпле бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләкне канәгатьләндерергә һәм түләүне гамәлгә ашырырга тиеш түгел.

6. Җирле үзидарә органы әлеге Нигезләмәнең 4 пункты нигезендә әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктында күрсәтелгән хокукый акт кабул ителгән көннән 5 календарь көн эчендә документлар тапшыра.

7. Җирле үзидарә органы тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 5 пункты нигезендә документлар тапшырганнан соң 10 календарь көн эчендә финанс-бюджет палатасы җирле үзидарә органына бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне түләү өчен бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары турында хәбәрнамәләр (алга таба – хәбәрнамә) яисә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү өчен җирле үзидарә органнарына акча бирүдән дәлиләнгән баш тарту турында җиткерә.

8. Финанс-бюджет палатасы әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында каралган барлык документлар да тапшырылмаган очракларда бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү өчен җирле үзидарә органына акча бирүдән баш тарта.

9. Җирле үзидарә органы хәбәрнамәне алганнан соң 20 календарь көн эчендә муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затка пенсиягә чыкканчы, бер тапкыр бирелә торган акчалата хак (бүләкләү) түләүне башкара.

10. Бер тапкыр акчалата бүләкләү рәвешендә хак бер тапкыр түләнә. Муниципаль вазыйфаны җирле үзидарә органында биләгәндә яисә пенсиягә чыкканнан соң граждан муниципаль хезмәткә кергәндә һәм алга таба җирле үзидарә органында муниципаль вазыйфаны биләүче затның вәкаләтләре туктатылганда яисә муниципаль хезмәттән азат ителгәндә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү яки бер тапкыр бирелә торган акчалата кызыксындыру кабат түләнми.

Тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата кызыксындыру яисә дәүләт вазыйфасыннан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк түләнә торган затларга пенсиягә чыгу сәбәпле, җирле үзидарә органында муниципаль вазыйфадан азат ителгәндә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү (хак) түләнми.

11. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү (хак) түләү факты хезмәт кенәгәсендә аерым тамга белән билгеләнә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2012 елның 29 декабрендәге
XXIII-3 номерлы карарына
кушымта №16

(Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 23 октябрендәге XXII-1 номерлы карары редакциясендә)

# Муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру тәртибе

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү фондын формалаштырганда вазыйфаи эш хакларын түләү өчен җибәрелә торган акчаларның суммасыннан тыш түләү өчен акчалар карала (бер елга исәпләгәндә):

1) класслы чин өчен вазыйфаи окладка (эш хакына) айлык өстәмәләр - дүрт вазыйфаи оклад күләмендә;

2) муниципаль хезмәттә тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәләр - өч вазыйфаи оклад күләмендә;

3) муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәләр (катлаулылык, киеренкелек, хезмәттә югары казанышлар, махсус эш режимы) - ундүрт вазыйфаи оклад күләмендә;

4) аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр - өч вазыйфаи оклад күләмендә;

5) еллык түләүле отпуск һәм матди ярдәм биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләү - биш вазыйфаи оклад күләмендә;

6) айлык акчалата кызыксындыру - унике вазыйфаи оклад күләмендә.